ук вакытта намазын да калдырмаган, дөнья дип динен ташламаган, иманлы мөселман, зур шәхес! Ул гомер буе татар халкын бәйсез, үз дәүләтле итү турында хыялланган, шуның өчен көрәшкән, Евразия туфраклары өстендә ислам байрагын күтәргән... Казан татары күзлегеннән карaганда, ул бәлки хыялый бер дәрвиш, утопияче булып та күренергә мөмкин, әмма вакыт Габдрәшит Ибраһимовның хаклыгын раслады, татар милләте – бәйсез булганда, Евразия халыклары ислам байрагы астында туплансалар гына исән калырга мөмкиннәр...

Габдрәшит Ибраһим да, Габдулла Тукай да ятим булганнар, күкрәкләре белән заманаңың бозлы диварларын ватып, үз максатларына барганнар, милләткә хезмәт иткәннәр. Тукай Казанга омтылган һәм 26 яшендә шунда янып бетеп, җир куенына кереп яткан, Габдрәшит Ибраһим кояш чыгышына таба ашкынган, Тукайдан соң да әле утыз ел яшәп, 1944 елның көзендә Токиода мәңгегә күзләрен йомган... Алар безгә икесе дә кадерле, икесенең дә хезмәтләре милләтнең алтын хәзинәсе булып тора, кешелек дөньясына хезмәт итә...

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһим Габдерәшит. Фәнни-биографик җыентык. – Казан, 2011.
2. Ибраһим Габдерәшит. Бөгрәдәлек көндәлеге. – Казан, 2013.
3. Ибраһимов Габдеррәшит. Дәүре галәм (Дөнья тирәли). Тәрҗемәи хәлем. – Казан, 2001.
4. Исхакый Гаяз. Әсәрләр. 15 томда. 6 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 203 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 1 т.: Шигырьләр. Поэмалар (1903–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.
6. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 2 т: Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). Җырлар дәфтәре. Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 400 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. 4 т: Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.

УДК 811.512.1

## ТЕОРИЯ ТЮРКО-ТАТАРСКОГО ЛИТЕРАТУРНОГО ЯЗЫКА: ТВОРЧЕСТВО ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ (ТЕЗИСЫ)

***И.Б. Баширова***
*ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ (Казань)*

В конце XIX – начале XX века татарский литературный язык функционировал в трех вариантах. В зависимости от адресата и содержания текстов, одни и те же писатели-просветители оформляли свои произведения: а) традиционным старотатарским с преобладанием арабо-персидских заимствований; б) традиционным старотатарским с преобладанием огузо-турецких слов и словоформ; в) традиционным старотатарским близким к татарскому разговорному языку. Все классики татарского народа, в том числе и Г. Тукай, в теоретическом плане резко отрицали традиционный тюрки, хотя в практическом плане, на начальном этапе творчества, все они, по-своему обновляя традицию, подражали и старотатарскому, и новоосманскому тюрки; они не писали на турецком языке, как утверждают некоторые наши ученые.
**Ключевые слова**: история татарского литературного языка, варианты письменного языка, арабо-персидские и огузо-турецкие заимствования, разговорный язык.

In late nineteenth – early twentieth century, the Tatar literary language functioned in three versions. Depending on the recipient and the content of the texts, the same writers filled their works with: a) the traditional Old Tatar with a predominance of Arab-Persian borrowings; b) the traditional Old Tatar with a predominance of Oguz and Turkish

words and phrases; c) the Old Tatar close to the spoken language. All the classics of the Tatar people, including G. Tukay, in theory rejected the traditional Turki, but in practical terms, at the initial stage of their writing, continued the tradition of writing in the Old Tatar Turki. This article analyzes the first (published 1905–1907.) works of G. Tukay that were written in the Old Tatar language version with a predominance of Arab-Persian borrowings, rather than the Turkish language as some of our scientists claim.
**Keywords:** history of the Tatar literary language, variants of the written language, Arabic-Persian and Oghuz-Turkish borrowings, spoken language.

## ТӨРКИ-ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ НӘЗАРИЯТЕ: ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫ (ТЕЗИСЛАР)

***И.Б. Бәширова***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ (Казан)*

Хәзерге тюркологиядә төрки телләрнең әдәби теле нәзарияте/теоретик нигезе дигәндә, язма телнең табигатен һәм вазифасын барлыкка китерә торган билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше күздә тотыла. Бу хакта танылган тюрколог Э.Р. Тенишев болай дип белдерә: «Әдәби тел тарихы белән шөгельләнгәндә, әдәби телнең табигатенә хас булган төп үзенчәлекләрен күрә белергә кирәк:1)ул билгеле бер дәрәҗәдә эшкәртелгән, шомартылган була, 2) функциональ-стилистик вариантлылыкка ия, 3) норма вариантлылыгына ия, 4) диалеклардан өстен һәм 5) традициясен-дәвамчанлыган саклый» [11: 72–73].

Татар халкының бөек шагыйреГабдулла Тукай иҗат итә башлаган XX гасырның бишенче елларында, төрки-татар әдәби теленең ун гасырдан артык үсш-үзгәреш традициясе булуы мәгълүм. Әлеге тарих, гомумтөрки гаилә кочагында, VI–VIII гасырларда рун язуларыннан башланып, IX–XI дәверләрдә, төркиләр ислам дине кабул иткәннән соң, гарәп графикасына күчеп, XII–XIII йөзләрдә Болгар дәүләтендә, XIII–XIV гасырда Алтын Урдада, XV–XVI йөзнең беренче яртысына кадәр Казан ханлыгында дәвам итела, аннан соң инде Мәскәү/Русия дәүләтенең Урта Идел буендагы төрки-татарларның теле буларак, эзлекле рәвештәкулланылышта була.

Әдипләр үзләренең иҗатларында, язма традицияне саклаганы хәлдә, һәр дәүләттә көн күрүче җирле халыкның җанлы сөйләмә/диалекталь үзенчәлекләре белән баета, эшкәртә, шомартабаралар: әдәби тел аерым төбәктә яшәүчеләрнең барысына да аңлаешлы, диалектлардан өстен булган хәлгә китерелә.Бу юнәлештә, төрки тел төшенчәсе, аерым төбәктә яшәүчеләрнең исеме-атамасын кабул итеп тәгаенләнә: Болгар төрки тел, Алтын Урда/Җучи Олысы төрки-кыпчак теле, Казан төрки-кыпчак – иске татар теле, Русия дәүләтендәге Урта Идел буендагы классик татар теле. XX гасыр башында, «Русия төркиләре»дигән төшенчә / атама рәсмиләштерелә [10: 21–232].

Дәверләр буена әдәбиләштерелүнең эзлекле баруы, хәрәкәттә булуы нәтиҗәсендә, үзенчәлекле язма норма ныгытыла: а) гарәп-фарсы алынмалары үз әлифбасы белән, катгый рәвештә үз чыганак теленең кагыйдәләре таләбенчә языла; ә) төрки-татар теленең сүзләре, билгеле бер дәрәҗәдә тотрыкланган, иске имля нигезендә дәвам итела. Аларның үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте язма телдәге вариантлылык күренешен барлыкка китерә. Татар сөйләмендәге 10 сузык авазны, гарәп теленең 3 шәкеле белән күрсәтергә, бер төрле генә әйтелә һәм языла торган бер тартык авазны, гарәп теленең 3–4 формасында язарга кирәк була һ.б.

Төрки-татар телендә, иҗтимагый тормышны алып бару өчен кирәк булу максатына ярашып, әдәбиязма телнең аерым сөйләм төрләретотрыклана, аң тарафыннан кабул ителә,функциональ стильләре дип яшәеш ала. Үзенә хас булган төрле жанрлары белән Рухани-диниәдәбият стиле дәвам ителә. Поэзия һәм проза жанрлары белән хәрәкәттә булган Сәнгати-матур әдәбият стиленең драма жанры, Иҗтимагый публицистика стиленең газета теле дигән үзенчәлеклежанрлары гамәлгә куела. Фәнни әдәбият стиле яңа тармаклары белән баетыла. Дәүләти-хокукый эш кәгазьләре, Эпистоляр-хатлар стиле, Көндәлек-һөнәри әдәбият стиле чор таләпләренә җавап бирү юнәлешендә яңара бара [3: 10–25]. Бу жанр/стильләрен яшәтә торган әдәби тел, адресатның кем булуына карап, өч төрле: а) гарәп-фарсы алынмалары, ә) угызтөрек алынмалары мул файдаланыла торган аристократ/абруйлы, б) татар халкының җанлы сөйләменә нигезләнгән халыкчан/гавами норма вариантла ры белән кулланылышта була. Менә шушы вакытта, татар халкының даһи шагыйре Габдулла Тукай беренче шигырьләрен яза башлый. Шагыйрь иҗа тына нисбәтән языла торган хезмәтләрдә, Г. Тукай – татар әдәби теленә нигез салучы / основоположник татарского литературный языка, дигән фикернең кабатлануы мәгълүм. Әмма «Габдулла Тукай. Энциклопедия» хезмәтендә, Г. Тукай иҗатының татар язма әдәби теле белемемәсьәләләре белән бәйләнеш-мөнәсәбәте, аерым тематик юнәлеш буларак күтәрелеп бирелми [16: 6–8]. XIX гасыр ахыры XX йөз башында беренче әсәрен яза башлаган классикларыбызның барысының да, шул исәптән, Габдулла Тукайның да, гарәп графикасы белән иске татар телендә иҗат итүләре мәгълүм. Без аларның әсәрләрен хәзерге татар әдәби теленә, кириллицага күчереп укыйбыз. Бу юнәлештә, катлаулы мәсьәләләрне аңларга һәм аңлатырга кирәк булуы күренә. Җөмләдән берсе – классик әдипләрнең иҗатына **татар язма әдәби теле тарихының бер дәвере итеп карау зарурлыгы**. Г. Тукайның күп кырлы, катлаулы иҗатын, татар әдәби язма теле тарихының бер буыны буларак тикшергәндә, үзенә кадәр салынган нигезнең мөһимлеген аңлап, аны камилләштерүче булуы аңлашыла. Габдулла Тукайның даһилы гы, мең еллар буена дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигатен һәм вазифасын зиһенгә алып, аны инкарь итмичә, бәлки тулаем мөмкинлеген файдалануы уңаенда, төрки-татар әдәби телен, аңа кадәр күрелмәгән югары дәрәҗәдә, үзенчә үстерә/яңарта белүендә чагыла. Әлеге эшчәнлекнең, татар әдәби телен өйрәнгәндә кабул ителгән тәртипне саклап, иске татар теленең язма төрләрендә ничек баруына кыскача (тезислар) рәвешендә тукталабыз.

1) Иске татар телнең гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланыла торган аристократ/ абруйлы юнәлешенең яңартылып дәвам ителүе. 1905 елда, Тукайның «Әлгасрел-җәдид»журналының чыгасы белдерелгән программада, «Голүмең бакчасында...»дигән шигыре басыла: Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран, / Сәгадәт бәхтемезгә калсын инсе, җинниләр хәйран, / Татар рифгате, шаны сикез кат күкләрә китсен / Әбәд-сәрмәт бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен, / Борынгы уйкуларны дөшенүбән улалым надим / Тәрәкъкый вә Тәгали йулларына улалым надим. ... Гыйлемле, белемле булыйк, Ходаем татарларны мәңге сәгадәт-бәхетле итсен, дөньяда болгарларның барлыгына ышандырыйк, төрле журналлар күбәйсен, милләтнең яшь каһарманнары кулында каләм булсын, йоклап ятмыйк, мәгариф мәйданында ат уйнатыйк... Шушы ук тема «Шәкерт, яхуд бер Тәсадеф», «И каләм!», «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел», «Пушкинә», «Гәзитә

мөрәттиб ләренә», «Хөрриятә» һ.б.шигырьләрендә дәвам ителә [14: 24–139]. Гыйлемгә-белемгә омтылу фикеренең бөеклеге, XI–XII гасырдан («Котадгу Билек», «Кыйссаи Йосыф»тан) башланып, болгар төркисе –төрки-кыпчак – иске татар телендә язылган дәверләр буена тасвир ителә килеп, XVIII гасыр ахыры – XIX йөзнең беренче яртысында,татар халкының талантлы фикер иясе – шагыйрьләре булган, Г. Утыз-Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б. иҗатында, иҗтимагый тормыш шартлары таләбенә җавап бирү юнәлешендә, тагын да югары күтәрелә. Әлеге авторлар үзләренең әсәрләрен,гомумтөрки нигезне саклаган хәлдә, укымышлы кешеләргә багышлап, алар аңлый торган гарәп вә фарсы алынмаларын мул кулланып, аристократ-абруйлы төрки тел белән иҗат итәләр. Яшь Тукай да, Аллаһы Тәгалә, Коръәни Кәрим сүзләре белән куәтләнеп, гыйлем-мәгърифәтле, затлы – зыялы булып, милләткә хезмәт итүнең зарурлыгы тасвирлана торган шигырьләр, нәкъ шул әсәрләрнең теле кебек язылырга тиеш дип аңлый һәм шулай яза. Димәк, Г. Тукай, әлеге нисбәттән ниндидер яңалык ача дип әйтә алмыйбыз, дәверләр буена гамәлгә куелып тормышка ашырыла торган язма ысул дәвам ителә. Бу юнәлештә, дини-рухани яшәеш белән бәйле һәм традиция буларак килә торган, Алла, Коръән, Фәрештә, Пәйгамбәр һ.б. төшенчәләр файдаланыла. Алла төшенчәсенең, Аллаһи, Илаһ, Хәкъ-Хак, Мәүла, Мәгъбуд, Раббе, Тәңре, Хода/Ходай, Хәзрәт, Шәкүр, Гафур һ.б. Әсмаи-Хөснә/Исме-Әгъзам күркәм исемнәре кулланыла. Аларның һәрберсе сүзмәгънә һәм грамматик чолганышында, сүз җаена туры китерелеп, сүз, сүзформа, сүзтезмә буларак,-берничә мәртәбә, мәсәлән, Аллаһы атамасы – 55 (15: 48–49), Ходай – 66 (15: 286–287), Тәңре – 45 (15: 176–177), Илаһ – 7 (15: 7), Мәүлә – 7 (15: 21), Раб/Раббасы – 4 (15: 91) һ.б. мәртәбә кабатланып бирелә.

Сүзлектә теркәлгәнчәкараганда, бу төшенчәләр дин тәгълиматына бәйле булган төп мәгънәләре белән аңлашыла. Авторның шигъри әсәрләрендә дә әлеге атамалар үзләренең асыл мәгънәләрен саклый, әмма иҗтимагый тормышта бара торган вакыйга-хәлләргә, авторның мөнәсәбәте нинди булуга һәм аның ничек итеп белдерелүенә карап, сүзмәгънә эчтәлегенең яңартылуы күренә. Лексик-семантик мәгънә эчтәлегендәге яңарышы дигәндә, традиция буларак килә торган төшенчә/атамаларда: а) мәгънәнең нигезе саклануы; ә) төрлесүзләрбелән грамматикчолганышындатөп мәгънәнең яңа төсмер алып киңәйтелүе; б)шәхси хис-кичерешләргә бәйле хәлдәге мөнәсәбәт чагылышында, сүзмәгънә эчтәлеге үзенең капма-каршысына әверелүе истә тотыла. Әлеге яңарыш нәтиҗәсендә, ягъни сүзләрнең лексик-семантик вариантлылыгы кебек катлаулы күренеше хасил булуын, ГабдуллаТукайның корама телдә язылган, халыкка аңлашылмый дип, кире кагыла торган беренче шигырьләрендә үк урын алуын ассызыкларга мөмкин. Мәкаләнең күләме белән чикләнеп, мисал өчен, аерым бер «Алла гыйшкына» («Алла яратсын өчен») шигыре алына. 10 икеюллыгында, 18 мәртәбә кабатлана торган әлеге сүзтезмә: Бар һөнәремезгә канигъ улмыйк Алла гыйшкына / Тәңренең лотфенә манигъ улмыйк Алла гыйшкына, – дигән соңгы юлында, Тәңре сүзе белән чиратлаштырыла, мәрхәмәтнә каршы килмик дип, традиция нигез мәгънәсен саклап кулланыла. Калган барлык очракларда: Алла яратсын өчен, дус булыйк, милләтнең күңелен аңа юнәлтик, омтылыйк, шул юлда тырышыйк, гайрәт итик, наданлык безне измәсен, гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын, дөньяны хәйран калдырыйк, милләтне күтәрергә күңелем ашыга, ашкына, мәгърифәт, һөнәр тусын, дус

булыйк, и Мөхәммәт өммәте дип, мөрәҗәгать итедә. «Алла яратсын өчен Тәңре мәрхәмәтенә каршы килмик» дигәндә, дини нигез сакланганы хәлдә, милләт, аң-акыл, гыйлем, мәгариф юлында тырышыйк дип, дөньяви сүзләр белән грамматик бәйләнеш-мөнәсәбәтендә, төп мәгънәнең эчтәлеге киңәйтелә. Нәтиҗәдә, аерым бер Аллаһы төшенчәсе нең төрле лексик-семантик вариантлары хасил була, язма әдәби тел берәмлегенең саны арта, колачы, кулланылыш даирәсе киңәйтелә [14: 46]. Шулай итеп, авторның гарәп-фарсы алынмалары мул файдаланылып язылган бер шигырендә, Аллаһы сүзе белдерә торган бер төшенчә/атаманың, туры-төп-дини мәгънәсе нигезендә,аның эчтәлегенә хас сәнгатьчә-дөньяви мөмкинлеге ачылуы белән, Г. Тукайның әдәби телебезне ничек итеп үстерүе/ камилләштерүе күзаллана. Бу юнәлештә тагын, Ходаем бәхтияр итсен һәм Мөхәммәт өммәте сүзтезмәләрнең мәгънә эчтәлегендә, татар милләте дип дәвам ителешенең ничек баруын күзәтергә була. Әлеге яңарышның төрле жанрларда (сатирик, мәхәббәт, публицистик, балаларга багышлап һ.б.) язылган әсәрләрендә ничек баруын җентекләп анализларга кирәк булачак. Сатирик шигырьләрдә, Аллаһы төшенчәсенең мәгънә эчтәлеге, үзенең капма-каршысына әйләндерелә: ...«Ишан, ишәкөкешер / Өкешмәктә (мактанышуда) мәгънә бар», – дип башлана торган шигырьдә: ...Булсаң син хайван надан / Синнән бигрәк мин надан / Ялкаулык та наданлык / Бүләк безгә Алладан» [14: 123] һ.б.

2) Иске татар теленең, угыз-төрек алынмалары мул файдаланыла торган ысулының дәвам ителеше. Г. Тукайның гарәп-фарсы алынмалары мул кулланылып языла торган шигырьләрендә, угыз төркеме телләренең җанлы сөйләменә хас булган үзенчәлекләрнең дә эзлекле файдаланылуы күзәтелә: бән, вар, идәлем, улаем, күстәрү, безем һ.б. Бу төрдәге сүз, сүзформалар,таш язмаларыннан ук, угыз-уйгыр-кыпчак кабилә телләренең катнашмасы булган гомумтөркидән килә торган язмачылыкның нигез/традициясен күрсәтә торган берәмлекләр булып санала [12: 35] иске татар теленең төрле чорында, теләсә кайсы жанр-стильдә язылган текстларда, төрле дәрәҗәдәге эзлеклелектә кулланылышта була; Г. Тукай иҗатының башлангыч чорында, гыйлем-белем, милләт язмышы турында язганда, аристократ/абруйлы төрки-татар телнең күрсәткечләре буларак, эзлекле рәвештә дәвам ителә. Г. Тукайның беренче тәнкыйтьчеләре тарафыннан, шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына үзенчә лекле мөнәсәбәт белдерелә: халыкчан тел берәмлекләре файдаланылган шигырь ләре күтәрелеп мактала да, гарәп-фарсы алынмалары күп кулланыл ган шигырьләре «төрек-госманлы телендә язылa» дип ассызыклана. Ф. Әмирхан: «иске вә яңа төрек әдәбияты тәэсире», автор өчен гөнаһ эш дип белдерә [1: 11–14]; Җ. Вәлиди: «Тукаевның беренче (шәкердлек) дәверендә, госманлычарак язган шигырьләре эчендәтәрҗемәләре юк диярлек дәрәҗәдә аз иде, ...Фатих әфәнде Тукаевның госманлыча язылган шигырьләрен тел җәһәтен яратмый һәм «Шүрәле», «Алтынга каршы»кеби-татарча шигырь ләренә бик зур кыйммәт бирә иде», – дип (4: LXI, XXXIX), Г. Ибраһимов: «Тукай кебек шагыйрьләр (башлангыч "Мөхәммәдия дәвере") байтак вакытлар ярым "Тәрҗеман", ярым госманлы тәэсирендә бардылар», – дип тәгаенли [6: 38]. Ш. Рамазанов: «Бер яктан, әле "төрки тел" дип аталган борынгы феодализм чорының корама "китап теле" дәвам итә. ...Тукай ике телдә – татар һәм төрек телләрендә язды», дип аларны санап күрсәтә [7: 58–61]. Г. Тукайның беренче шигырьләре госманлы-төрек телендә язылган, дигән фикер ныгытыла. Иң гаҗәбе, безнең көннәрдә, тагын

да пафослырак булып, әлбәттә чынбарлыкка туры килмәгәнчә: «...Кардәш төрек халкының теле барлык төрки милләтләр өчен әдәби теле буларак та хезмәт иткән, Г. Тукайның да иҗатын башлаган вакытта кайбершигырьләре сиксән-туксан проценты төрек телендә язылган», «Габдулла Тукай, классик шагыйрьләребезнең күбесе кебек үк иҗатының башлангыч чорында, госманлы телендә язган. Татарның барлык мәдрәсәләрендә дә иске төрек теле фән буларак укытылган, ә аңарда әсәрләр иҗат итү югары өслүб үрнәге саналган, үзенә күрә бер мода булган» дип, Г. Тукайны модага иярүчегә саный торган методологик хата фикерләр язылa [8: 46]. Без, татарларда, гарәп теленең дә, төрек-госманлы теленең дә, һич бер вакытта да, тулаем әдәби тел буларак вазифа үтәмәүләре, татар әдәби теленең, гомумтөркидә нигезләнеп, гасырлар буена килә торган үз тарихы булуына игътибар ителми. Тикшерү барышында, бу шигырьләрнең берсенең дә төрек телендә түгел, бәлки татар әдәби телендә гасырлар буена килә торган, аристократ/абруйлы юнәлешендә язылуы күренә [2: 74–82]. Әлеге мәсьәлә, Л. Җәләйнең: «Тукай телен өйрәнү-татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз», – дип раславында билгеләнә [5: 11].

3) Иске татар телендәге, халык авыз иҗаты әсәрләре һәм җанлы сөйләменә нигезләнгән, гавами ысулның илаһи югарылыкка күтәрелеп эшкәртелүе. Г. Тукайның аристократ / абруйлы шигырьләре белән бер үк вакытта: Ник йоклыйсың мужик? / Яз җитте һәм үсте / Чирәмләр йортында; / Тор, уян, күтәрел! / Үз-үзеңә кара:/кем идең, кем булдың? – дип, «мужик»-ның үз телендә, асылда, халыкның җанлы сөйләмендәге сүз, сүзформа, сүзтезмәләре кулланылып та иҗат ителә [14: 31]. Татар әдәби теленең бу юнәлеше, XII гасыр Идел буе Болгар дәүләтендә, Әхмәд Ясәвинең: «Аять, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ / Мәгънәсенә йиткәнләр йиргә куяр бүркине...», – дип, суфи шагыйрьнең фәкыйрьләр, гарипләргә багышлап, аңлауны җиңеләйтү максатыннан, гарәп-фарсы алынмаларын азайтыбрак, төркиләрнең барысы өчен дә мәгълүм булган уртак сүз, сүзформаларын кулланып язылган «Диване хикмәтләр»е белән башлана [9: 139]; XVIII–XIX гасырлардагы «Илаһи бәетләр»дән, Баһави, Г. Кандалый, Ә. Уразаев-Кормаши, М. Акмулла һ.б. авторларның әсәрләре белән дәвам ителә. Г. Тукай үзенең иҗатында, халыкчан тел чараларын эстетик эчтәлекне сәнгатьчә тасвирлау югарылыгына күтәрә: «...әдәбиятымызның асылы, җәүһәре булган безнең Казан теле...» икәнлегенә инануын белдерә [13: 118], традиция булып килә торган алымнарны үзенчә яңартып үстерә. Бу хакта бик күп мәкаләләр язылган, монографияләр басылган, диссертацияләр якланган.

**Нәтиҗә.** Төрки-татар әдәби теле нәзариятенең тарихи нигезе буларак тикшерелә торган күренеш, ягъни Болгар-Казан/иске татар телендә, XII–XIII гасырлардан, аерым авторларның әсәрләрендә, адресатка карап: а) гарәп-фарсы алынмалары, ә) угыз-төрки сүз, сүзформалары белән туендырылган аристократ-абруйлы һәм б) халык авыз иҗаты тәэсирендә, татарларның үз сөйләмә тел байлыгын файдаланып язу юнәлешләре, татар әдәби теле тарихында Г. Тукай иҗатында бергә берләшә.Шагыйрь әсәрләрендә, бер яктан, язма традициянең куәтле мөмкинлеге, аның һич бер вазифасы инкяр ителми, икенче яктан, авторның таланты беләнсөйләмә тел дә, әдәби тел вазифасын үтәрлек, ягъни эстетик эчтәлекне тасвирлап бирерлек сәнгати чара югарылыгында әдәбиләштерелә. Татар әдәби теле үзенең алтын чоры дигән дәверендәге үсешенә күтәрелә. Хәзерге татар телендә, Г. Тукай

әсәрләренең телүзенчәлеге өйрәнелгәндә, менә шушы нигезләргә игътибар ителеп, аларда башланган мөмкинлек бәйләнеш-мөнәсәбәтендә яктырту сорала. Г. Тукай иҗатында гасырлар буена эзлекле кулланылышта булган төрки-татар әдәби теленең көче-куәте-байлыгы күтәрелеп эшкәртелә, норма буларак ныгытыла һәм норма вариантлары белән бергә файдалана алуы күрсәтелә. Әлеге мөмкинлекне төгәлрәк күзаллау максатыннан, авторның үз вакытында, гарәп графикасы белән язылган/басылган аерым әсәрләрен, кириллга күчерелгән шигырьләре белән бергә, чагыштырып бирү яхшы булыр иде. Г. Тукай теле – саф татар теле, дигән беркатлы бәяләрдән саклану булыр иде.

ӘДӘБИЯТ


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр: дүрт томда. 4 том: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 390 б.
2. Бәширова И.Б. Тукай төрек телендә шигырь язганмы ? // Казан утлары. – 2015. – № 4. – Б. 110–120.
3. Бәширова И.Б. Татар стилистикасының теоретик нигезләре. – Казан: КДУ, 2005.
4. Вәлиди Җамал. Мөхәммәдгариф угълы Тукаев // Г. Тукаев Мәҗмугаи асәре, 1914.
5. Җәләй Л. Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. – 1938. – № 3. – Б. 58–66.
6. Ибраһимов Г. Яңа татар теленең беренче баскычларында // Сайланма хезмәтләр. – 2007. – Б. 32–39.
7. Рамазанов Ш.А.Татар теле буенча очерклар. –Казань: Таткнигоиздат, 1954. – 200 б.
8. Сафиуллина Р. Кутлу һәм аның олы мәхәббәте // Идел. – 2015. – № 4. – Б. 44–46.
9. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 1 т: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 415 б.
10. Татар әдәби теле тарихы (XШ гасыр – XX йөз башы). 1 т.: Фонетика. Графика:язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – Казан:ТӘҺСИ, 2015. – 696 б.
11. Тенишев Э.Р. Принципы составления исторических грамматик и историй литературных тюркских языков // Сов. Тюркология. – 1988. – № 1. – С. 67–78.
12. Тенишев Э.Р.Тюркоязычных письменных памятников языки // Языки мира. Тюркские языки. – Бишкек, 1997. – С. 35–46.
13. Тукай Г. Әсәрләр: Дүрт томда. 4 т.: мәкаләләр, очерклар һәм фельетоннар (1909–1913). – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 288 б.
14. Тукай Г. Әсәрләр: биш томда. 1 т.: шигырьләр, поэмалар (1901–1908). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 406 б.
15. Тукай Габдулла. Шигърият теле. Сүзлек. 2 китапта. – Казан: Мәгариф, 2009.
16. Тукай Габдулла. Энциклопедия (баш. мөх.З.З. Рәмиев). – Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. – 864 б.


УДК 76

# ИЛЛЮСТРАЦИИ ХУДОЖНИКОВ НАЧАЛА XX ВЕКА К ПРОИЗВЕДЕНИЯМ Г. ТУКАЯ


***Ф.Г. Вагапова***

*Казанский (Приволжский) федеральный университет (Казань)*



В статье анализируются иллюстрации к детским произведениям Г. Тукая, выполненные художниками начала XX в. Отмечается, что в создании иллюстраций принимали участие профессиональные художники, а также художники, не имевшие специального художественного образования. Иллюстрации к стихам Г. Тукая позволили проследить генезис и динамику развития татарской книжной графики начала XX века. Автором сделан вывод, что в творчестве художников начала XX в. прослеживаются черты, характерные для восточной миниатюры, русской лубочной картинки, а также стилистики искусства модерн.



**Ключевые слова:** восточная миниатюра, детская книга, иллюстрация, искусство, лубок, модерн, художник.